Республика Татарстан
**СОВЕТ**
**ЛЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Школьная, д. 1,
с. Ляки, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Мәктәп урамы, 1 йорт,
Ләке авылы, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru


**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 14 декабре №16

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затына хезмәт өчен түләү нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 19 нчы апрелендәге 2 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы (ред. 13.03.2020) Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Ләке авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затының хезмәткә түләү нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 19нчы апрелендәге 2 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымта «Сарман муниципаль районы «Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең сайланулы вазыйфаи затына хезмәт өчен түләү турында нигезләмәгә» түбәндәге эчтәлекле 6,7,8 пунктлар өстәргә:

«6. Даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затның еллык түләүле отпуск төп түләүле отпусктан һәм өстәмә түләүле отпусктан тора.

7. Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләгән затлар өчен ел саен түләнә торган төп түләүле отпуск дәвамлылыгы муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә, ләкин 30 календарь көннән дә ким булмаска тиеш.

8. Тиешле еллар эшләгән өчен еллык өстәмә түләүле отпускның дәвамлылыгы муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затка муниципаль вазыйфаны биләгән һәр ел өчен календарь көн, муниципаль хезмәт вазыйфасын, шулай ук

дәүләт вазыйфасын һәм дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгән өчен бер календарь көн исәбеннән исәпләнә. Еллык төп түләүле отпускның һәм муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче зат өчен, тиешле еллар эшләгән өчен еллык өстәмә түләүле отпускның гомуми дәвамлылыгы 45 календарь көннән арта алмый.»

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы Л.И.Шәрипова